КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 22 май г.Казань № 389

Гамәлгә ашырылуы Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган беренче бала тууга (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә айлык түләү билгеләү һәм аны башкару буенча Россия Федерациясе вәкаләтләре бирелә торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары карамагындагы оешмалар исемлеген раслау турында

«Татарстан Республикасында беренче бала туугa (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә, айлык түләүне билгеләүне һәм гамәлгә ашыруны оештыру турында» 2018 ел, 11 апрель, ТРЗ-18 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Гамәлгә ашырылуы Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган беренче бала туугa (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә айлык түләү билгеләү һәм аны башкару буенча Россия Федерациясе вәкаләтләре бирелә торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары карамагындагы оешмалар исемлеген расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 22 май, 389 нчы
карары белән расланды

Гамәлгә ашырылуы Россия Федерациясе субъектларының
дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган беренче бала тууга
(уллыкка алынуга) бәйле рәвештә айлык түләү билгеләү һәм аны башкару буенча
Россия Федерациясе вәкаләтләре бирелә торган Татарстан Республикасы
дәүләт хакимияте органнары карамагындагы оешмалар
ИСЕМЛЕГЕ

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе.

___